**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Электрон парамагнит резонансын куллануга яисә үстерүгә күренекле өлеш керткән өчен Е.К. Завойский исемендәге халыкара премия бирү буенча оештыру комитеты составына һәм Татарстан Республикасының М.И. Мәхмүтов исемендәге дәүләт премиясен бирү комитеты составына үзгәрешләр кертү турында**

Кайбер затларның башка эшкә күчүләре һәм аларның вазыйфалары атамалары үзгәрү белән бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең Е.К. Завойский исемендәге халыкара премияне гамәлгә куючылар составына керүе турында» 2010 елның 17 ноябрендәге ПУ-750 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 1 февралендәге ПУ-102 номерлы һәм 2018 елның 13 апрелендәге ПУ-309 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Электрон парамагнит резонансын куллануга яисә үстерүгә күренекле өлеш керткән өчен Е.К. Завойский исемендәге халыкара премия бирү буенча оештыру комитеты (алга таба – Оештыру комитеты) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Оештыру комитеты составыннан Р.Т. Борһановны, Р.Р. Гыйматдиновны, А.М. Сибагатуллинны чыгарырга;

б) Оештыру комитеты составына Һадиуллин Илсур Гәрәй улын – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрын кертергә, аны Оештыру комитеты рәисе итеп расларга;

в) Оештыру комитеты әгъзасы А.А. Калачевның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәге» федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесе директоры, Россия фәннәр академиясе профессоры, Оештыру комитеты рәисе урынбасары (килешү буенча)».

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының М.И. Мәхмүтов исемендәге дәүләт премиясен гамәлгә кую турында» 2017 елның 26 декабрендәге ПУ-1169 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2018 елның 13 октябрендәге ПУ-729 номерлы һәм 2020 елның 4 мартындагы ПУ-144 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан

Республикасының М.И. Мәхмүтов исемендәге дәүләт премиясен бирү комитеты (алга таба – Комитет) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комитет составыннан Р.Т. Борһановны чыгарырга;

б) Комитет составына Һадиуллин Илсур Гәрәй улын – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрын кертергә, аны Комитет рәисе итеп расларга;

в) Комитет әгъзасы А.И. Шәмсетдиновның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Казан шәһәренең «Адымнар – белемгә һәм бердәмлеккә юл» полилингваль комплексы» дәүләт автоном гомуми белем бирү учреждениесе директоры (килешү буенча)».

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2021 ел, 31 август
№ ПУ-682